Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл Советы

# КАРАРЫ

03 март 2020 ел № 86

Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәренә пенсиягә чыгу белән тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеген кызыксындыру максатларында

Колшәрип авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәренә пенсиягә чыгу белән тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмәне расларга (Кушымта).
2. Әлеге карарны Колшәрип авылы Тукай урамы 50нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар халыкка рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Колшәрип авыл җирлеге башлыгы Т.М. Бурмистрова

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Колшәрип
авыл Советының 2020 елның
03 мартындагы 86 нче номерлы
карарына кушымта

Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәренә пенсиягә чыгу белән тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында
Нигезләмә

1. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге № 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәренә пенсиягә чыгу белән тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә (алга таба - бер тапкыр бирелә торган бүләкләү).

2. Муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгубеләнмуниципаль хезмәттән азат ителгәндә, эштән азат ителгән көнгә билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча аның айлык акчалата түләве биш мәртәбә арттырыла, муниципаль хезмәт стажы булганда, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен аның дәвамлылыгы исәпләп чыгарыла:

- 2019 елда 16 ел 6 ай,
- 2020 елда 17 ел,
- 2021 елда 17 ел 6 ай,
- 2022 елда 18 ел,
- 2023 елда 18 ел 6 ай,
- 2024 елда 19 ел,
- 2025 елда 19 ел 6 ай,
- 2026 һәм аннан соңгы елларда 20 ел

һәм муниципаль хезмәткәрнең һәр киләсе тулы елы өченөстәмә рәвештә 0,5 , ләкин муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата кереме күләменнән ун тапкыр дан артмаган күләмдә түләнә.

Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат иткән көнгә билгеләнә.

3. Әлеге нигезләмәнең максатлары дипмуниципаль хезмәттән тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыкканда, картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәч, яки картлык буенча хезмәт пенсиясен вакытыннан алда, яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясен билгеләгәндә «Иминият пенсияләре турында» 28.12.2013 № 400-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда эштән азат итү күздә тотыла.

4.Муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү тәртибе һәм күләмнәрен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата түләү составына түбәндәгеләр керә:

вазыйфаи оклад;

сыйныф чины өчен оклад;

муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү.

5. Пенсиягә чыгу белән муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган бүләкләү тәртибе турындагы карар Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл башкарма комитеты

җитәкчесе тарафыннан кабул ителә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле муниципаль хезмәткәрне эштән чыгару турында карар кабул ителү белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл башкарма комитеты (алга таба - җирлекнең башкарма комитеты) тиешле еллар эшләгән өчен, пенсиягә чыгу беләнмуниципаль хезмәткәрне эштән азат итүгә 30 календарь көн кала Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба - Финанс-бюджет палатасына) түбәндәге документларны тапшыра:

- муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата эчтәлеге турында белешмә;

- муниципаль вазыйфада, дәүләт һәм муниципаль хезмәттә җитәкче һәм кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган эш стажы турында белешмә;

- сыйныф чинын бирү, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата эчтәлеге составына керә торган вазыйфаи окладка өстәмәләр билгеләү турындагы карардан өземтәләр;

- кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билет күчермәләре;

- җирлек Башкарма комитетының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан таныкланган форма (кушымта) буенча башкарылган бер тапкыр бүләкләү исәбе;

- муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм муниципаль хезмәткәрнең эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.

7. Әлеге нигезләмәнең 6 пункты нигезендә документлар бирелү вакытыннан алып 5 эш көне дәвамында финанс-бюджет палатасы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл Советына (алга таба - җирлек Советы) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлеге бюджетыннан (алга таба –җирлек бюджеты) муниципаль хезмәткәргә пенсиягә чыгубеләнбер тапкыр бирелә торган бүләкләү турында карар проектын җибәрә, я авыл җирлеге башкарма комитетына, әлеге нигезләмәнең 6 пунктында каралганча барлык документлар да бирелмәгән очракларда,мотивацияләнгән нигездә пенсиягә чыгубелән бер тапкыр бирелә торган бүләкләүкүләмен билгеләүдән баш тарта.

8. Финанс-бюджет палатасы карар кабул итү вакытыннан алып 10 көн эчендә муниципаль хезмәткәргә пенсиягә чыгубеләнбер мәртәбә бүләкләү өчен бюджет ассигнованиеләре турында һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары хакында хәбәр итә.

9.Авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтелгән хәбәрнамәләр нигезендә, муниципаль хезмәткәргә пенсиягә чыгу уңаеннан, җирлек Советы тарафыннан муниципаль хезмәткәргә пенсиягә чыгу беләнбер тапкыр бирелә торган түләүне башкара.

10.Пенсиягә чыгу белән бер тапкыр бирелә торган бүләк бер тапкыр түләнә. Гражданин тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыкканнан һәм муниципаль хезмәт туктатылганнан соң, муниципаль хезмәткә кабаттан кергәндә әлеге Нигезләмәдә каралганча бер тапкыр бирелә торганбүләкләү кабат бирелми.

11.Пенсиягә чыгубелән бер тапкыр бирелә торган бүләк хезмәт кенәгәсендәбилгеләнә.

Колшәрип авыл җирлеге башлыгы Т.М. Бурмистрова

Әлмәт муниципаль районы Колшәрип
авыл җирлегенең пенсиягә чыгу
белән муниципаль хезмәткәргә
тиешле еллар эшләгән өчен
бер тапкыр бирелә торган бүләкләү
тәртибе һәм күләмнәре турында
Нигезләмәгә кушымта

Тиешле еллар эшләп пенсиягә чыгу белән бер мәртәбә
бирелә торган бүләкне түләү тәртибе һәм күләме

| | |
|---|---|
| Фамилиясе, Исеме, Атасының исеме | |
| Туган көне | |
| Муниципаль хезмәт вазыйфасының атамасы | |
| Җирле үзидарә органы исеме | |
| Айлык акчалата керем күләме (сум) | |
| Муниципаль хезмәт стажы (тулы еллар)) | |
| Бер тапкыр бирелә торган бүләк түләү өчен айлык хезмәт хакының саны | |
| Бер тапкыр бирелә торган бүләк (сумнарда) | |

Җитәкче

Баш хисапчы